**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.09.2025 № 1087

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының "эксперт комиссиясен төзү турында" 2016 елның 29 августындагы 779 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Эксперт комиссиясе төзү турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 29 августындагы 779 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 10 мартындагы 123 номерлы, 2020 елның 03 сентябрендәге 684 номерлы, 2020 елның 25 ноябрендәге 979 номерлы, 2022 елның 15 мартындагы 269 номерлы, 2025 елның 21 августындагы 919 номерлы күрсәтмәләре нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Күрсәтелгән карар белән расланган балалар алып торган гаиләләрдән балаларны дәүләт оешмаларына кайтару очракларын анализлау буенча муниципаль эксперт комиссиясе турындагы нигезләмәдә:

7 бүлекнең 7.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.1. Комиссия утырышы карау өчен рәсмиләштерелгән материаллар булганда уздырыла.».

7 бүлекнең 7.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.5. Комиссия секретаре әзерләгән утырыш беркетмәсе утырышны уздыру көнендә рәис һәм секретарь тарафыннан мәҗбүри имза салынырга тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин